**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**
**ТУКАЙ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ**
**«ТЕЛӘНЧЕ-ТАМАК АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ»**
**МУНИЦИПАЛЬ БЕРӘМЛЕГЕ СОВЕТЫ**

# КАРАР

06 апрель 2016 ел № 6/1

«Тукай муниципаль районы Теләнче-Тамак авыл җирлеге Советы депутаты статусы турындагы нигезләмәне раслау хакында» 2005 елның 29 декабрендәге 17 номерлы муниципаль берәмлек Советы карарына үзгәрешләр кертү турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы, «Россия Федерациясендә муниципаль хезмәт турында» 2007 елның 2 мартындагы 25-ФЗ номерлы, «Коррупциягә каршы тору турында» 2008 елның 25 декабрендәге 73-ФЗ номерлы, «Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» 2008 елның 25 декабрендәге 303-ФЗ номерлы Федераль законнар, Тукай районы прокуроры протесты нигезендә муниципаль берәмлек Советы

**КАРАР БИРДЕ:**

1. «Тукай муниципаль районы Теләнче-Тамак авыл җирлеге Советы депутаты статусы турындагы нигезләмәне раслау хакында» 2005 елның 29 декабрендәге 17 номерлы муниципаль берәмлек Советы карарына үзгәрешләр кертергә:

1) 4 статьяның 1 өлешенә түбәндәге эчтәлекле 12 пунктны өстәргә:

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон, «Коррупциягә каршы көрәш турында» 2008 елның 25 декабрендәге 273-ФЗ номерлы Федераль закон, «Дәүләт Вазыйфаларын биләүче затлар һәм аларның керемнәренә башка затлар чыгымнарының туры килүен тикшереп тору турында» 2012 елның 3 декабрендәге 230-ФЗ номерлы Федераль закон, «Аерым категориядәге затларга Россия Федерациясе территориясеннән читтә урнашкан чит ил банкларында счетлар (кертемнәр) ачуны һәм булдыруны, акчалар һәм кыйммәтле әйберләр саклауны, чит ил финанс инструментларыннан файдалануны тыю турында» 2013 елның 7 маендагы 79-ФЗ номерлы Федераль закон белән билгеләнгән чикләүләрне, тыюларны, бурычларны үтәмәү;

2) 4 статьяның 7 өлешендәге 7 пунктын яңа редакциядә бәян итәргә:

«Россия Федерациясе гражданлыгын туктату, чит ил гражданлыгы - Россия Федерациясе халыкара шартнамәсендә катнашучы чит ил гражданлыгы туктатылу, аның нигезендә чит ил гражданлыгы булган Россия Федерациясе гражданы чит дәүләт гражданлыгы сайланырга, аларга чит дәүләт гражданлыгы алырга йә яшәүгә рөхсәт алу яисә Россия Федерациясе гражданының чит ил территориясендә даими яшәү хокукын раслаучы башка документ алырга хокуклы, аның нигезендә чит ил гражданлыгы булмаган Россия Федерациясе халыкара шартнамәсендә катнашучы булып тормаган, җирле үзидарә органнарына сайланган булырга хокуклы»;

3) 15 статьяның 1 өлешенә түбәндәге эчтәлекле 8 пунктны өстәргә:

«Коррупциягә каршы көрәш турында» 2008 елның 25 декабрендәге 273-ФЗ номерлы Федераль закон, «Дәүләт вазыйфаларын биләүче затлар һәм аларның керемнәренә башка затлар чыгымнарының туры килүен тикшереп тору турында» 2012 елның 3 декабрендәге 230-ФЗ номерлы Федераль закон, «Аерым категориядәге затларга Россия Федерациясе территориясеннән читтә урнашкан чит ил банкларында счетлар (кертемнәр) ачуны һәм булдыруны, акчалар һәм кыйммәтле әйберләр саклауны, чит ил финанс инструментларына ия булуны һәм (яисә) алардан файдалануны тыю турында» 2013 елның 7 маендагы 79-ФЗ номерлы Федераль закон белән билгеләнгән чикләүләрне, тыюларны, бурычларны үтәргә»;

4) 15 статьяның 1 өлешенә түбәндәге эчтәлекле 9 пунктны өстәргә:

«Россия Федерациясенең норматив хокукый актларында билгеләнгән тәртиптә вазыйфаи бурычларын үтәгәндә мәнфәгатьләр конфликтына китерә торган яисә китерергә мөмкин булган шәхси кызыксынуы барлыкка килү турында хәбәр итәргә, шулай ук мондый конфликтны булдырмау яисә җайга салу буенча чаралар күрергә»;

5) 17 статьяның 1 өлешенә түбәндәге эчтәлекле 5 пунктны өстәргә:

«счетлар (кертемнәр) ачарга һәм аларга ия булырга, Россия Федерациясе территориясеннән читтә урнашкан чит ил банкларында кулдагы акча һәм кыйммәтләрне сакларга, чит ил финанс инструментларына ия булырга һәм (яки) файдаланырга»;

6) 17 статьяның 2 өлешен яңа редакциядә бәян итәргә:

«Депутат тарафыннан беркетмә чараларына, хезмәт командировкаларына һәм бәясе өч мең сумнан арткан башка рәсми чараларга бәйле рәвештә алынган бүләкләр муниципаль милек дип таныла һәм «Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районының Бетькин авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге советына акт буенча тапшырыла. Беркетмә чарасына бәйле рәвештә үзе алган бүләкне тапшырган депутат аны Россия Федерациясе норматив хокукый актларында билгеләнгән тәртиптә сатып алырга мөмкин».

2. Әлеге карарны җирлекнең мәгълүмат стендларында һәм ТР рәсми хокукый мәгълүмат порталында игълан итәргә.

3. Әлеге карар рәсми басылып чыккач үз көченә керә.

Муниципаль берәмлек башлыгы,
Совет рәисе Р.Ш.Нәҗметдинов